**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИКОЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422627 , с.Никольское ,
ул. Центральная , д 35
тел: 4-31-44**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422627 Никольский авылы,
Ээзкурамы , 35 нчыйорт,
Тел : 4-31-44**

**2021елның «29» гыйнвары** **1 номер**

**К А Р А Р**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә карар бирәм**:**

1. 1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлегендә, 1, 2 кушымталар нигезендә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Башкарма комитетының» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында «2020 елның 30 гыйнварындагы 1номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo/tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Э.Х.Алеев**

*2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы*
*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль*
*районының Никольский авыл җирлеге*
*Башкарма комитеы*
*карарына 1кушымта*

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе ( сум.) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны житкерү | 3778,40 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 886,58 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1760,00 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

*2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы*
*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль*
*районының Никольский авыл җирлеге*
*Башкарма комитеы*
*карарына 2кушымта*

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе ( сум.) |
| --- | --- |
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 278,40 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм кирәкле башка предметларны җиткерү | 3500,00 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 886,58 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1760,00 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |